Фәнзаман БАТТАЛ

14 декабрь, 2008 ел

# Ул янганда милләт җылына

Гомер диген... Хәмит Латыйфның яңа китап чыгару өчен туплаган шигырьләрен кулга алгач, бер вакыйга искә төште. Моннан утыз ел элек, мин әле Түбән Камада яшәгән чакта, Уфа ягының Илеш районыннан шул калага килеп төпләнгән яңа дусларым мине бер егет белән таныштырдылар: «Безнең авылдаш бу, яхшы рәссам, дуслыкны кадерли торган егет...» Аның белән, ниндидер эш-йомыш төшеп, күрше шәһәрләрнең берсенә юлга да чыктык. Иҗат турында сөйләшәбез.

– Яңа рәсемне ясый башлаганчы, иң әүвәл аны тулаем күз алдына китерү кирәктер инде, – дим егеткә. – Әдәбиятта, мәсәлән, шулай: язу өстәле янына утырганчы, язар әсәреңне яттан диярлек алдан белү кирәк...

Әлегә җитди, уйчан күренгән егет серле генә көлеп куйды:

– Юк, иң әүвәл мин рәсемемнең мәгънәсе, кеше күңеленә нинди фикер, тәрбия орлыгы салачагы турында уйланам. Урысча итеп тә әйтсәк, иң беренче чиратта мысыл кирәк.

Бу юлы мин дә көлдем. «Мысль» сүзен «саф татарча» һәм телен бөгәрләми, иреннәрен уйнатмый гына үзебезчә әйтүеннән генә түгел, бәлки иҗат кешеләренең һәркайсы өчен иң беренче чиратта фикер кирәклеген искә төшерә белүеннән дә...

Кыскасы, күңелле, үзара аңлаша белүле танышлык булды ул. Шуннан соң бу егетне югалттым мин – ул үзе яшәгән якларына кайтып китте ул чак, ә мин Казанга күчтем. Дистә еллар үтә торгач, исеме дә, төсе дә онытыла башлады кебек. Фамилияләребезне дә әйтешмәгән идек, җитмәсә... Әмма уйчан сүзләре, үзенчәлекле фикерләре онытылмады егетнең. Инде дә чирек гасыр чамасы вакыт үткәч, каршыма ак чәчле ир килеп басты. Кайда диген?! Үзебезнең Язучылар йортында!..

– Хәтерлисеңме син мине, Фәнзаман, Түбән Камада танышкан рәссамны – Хәмит Латыйф дигән кешене?

Таныдым, әлбәттә. Шул ук вакытта гаҗәпкә дә калдым: рәсем сәнгатенә ныклап җигелгән һәм шул мәсләгендә зур уңышларга ирешүе белән бер үк мәлдә инде шактый гомер шигырьләр дә яза икән! Хәтта рәсемнәре белән шигырьләрен аралаштырып туплаган һәм яңа гына чыгарган җыйнак кына китабын бүләк итте, танышу өчен шактый кульязмаларын да бирде. Шунысына да игътибар иттем: шигырьләренең күпчелеге кыска – берәр-икешәр строфалы (куплетлы) гына. Дөресен әйтим, сагайта мине артык кыска шигырьләр һәм... һәм алар хакында балачакта ук укылган һәм истә калган бер акыл иясенең кызыклы һәм гыйбрәтле гыйбарәсе дә искә төшеп елмайта. Ул болай дигән: «Кыска шигырьне беренче укуда ук аңлап бетермәсәң, икенче кат укы. Алай да аңламасаң, өченче кат укы. Инде һаман да аңламыйсың икән, шуны бел: йә ул шигырьне язган язучы, йә үзең ахмак». Чыннан да, кыска шигырь, гадәттә, һичьюгы ике мәртәбә укыла. Чөнки автор бәләкәч кенә шигырьдә үзенең тел байлыгына да шик калдырмаска һәм шуңа күзеңне ачтырырлык, уйга калдырырлык фикер, мәгънә орлыкларын да «тамызып» куя белергә тиеш! Алар гына да җитми әле!.. Синең шигырь укучының үз фәлсәфәсен дә уятуга җирлек тудырсын. Кабатлап әйтәм: кыска шигырь шалтыр-шолтыр гына укып

үтә торган декламация түгел һәм шул үзенчәлеге белән кадерле дә!

Хәмит белән кабат очрашканнан соң, аның шигырьләрен әледән-әле укырга күнектем. Әйтик:

– Күчәргә! – дип өстән Указ булган...
Шомлы дөнья калган тараеп...
Нигезләрдә калган Ялган белән
Шайтан таяклары саргаеп.

Җиңел акыл белән генә укып үтүче өчен әллә ни юк монда. Ләкин шагыйрьнең әйтеп бетермәгән, «чәйнәп каптырмаган» фикерләренә дә үтеп керә белсәң, үзебезнең чор фаҗигаләре бер-бер артлы күз алдыннан үтә башлый. Мәсәлән, бу шигырьне укып чыккач, минем күз алдыма үзем туып-үскән Минзәлә ягындагы әле кайчан гына гөрләп, кайнап торган дистәләрчә авыллар искә төшә дә, аларның хәзерге әрем, билчән, шайтан таяклары баскан нигезләре, ятим калган зиратлары, корыган чишмәләре сагышка, хәсрәткә сала. Төннәр суынган кебек була кайчак... Кайсы гына чорларның нинди генә «акыллы башлары» указлар, карарлар белән үтермәде-бетермәде ул авылларны! Кукуруз чәчәргә басуларны киңәйтү өчен дә, бәләкәй авылларны зур авылларга күчереп, шәһәр белән авыл арасындагы аермалыкларны бетерү өчен дә, мәктәпләрдә балалар саны азаюын сәбәп итеп тә...

Хәмитнең туган, тәпи баскан авылы Бүләр дә күз алдыма килә. Мин анда Хәмитнең бу дөньяда барлыгын да белмәгән егет чагымда сәйран кылган идем. Ак каеннарга сыенган, урман куеныңда тезелешеп киткән егерме йортлык ул авыл миңа җир оҗмахы сыман тоелган иде. Хәзер инде ул да юк... Шуны йөрәге аша үткәреп язмады микән ул теге шигырен? Нәкъ шушы урында иҗатының сагышлы да, моңлы да булуын, ятимлекләр ачысын татый-татый үсеп, үз мәсләгенә омтылып яшәгәнлеген дә йөрәк аша кичергәч, күңелгә сәер дә, шомлы да уй кереп оялый: авылсыз гына түгел, балачактан ук ата-анасыз да калган адәм балаларына Ходай ни өчен фикерләү, кабилият кебек асыл сыйфатларны өеп-өеп бирә? Тетрәнә-тетрәнә, үкси-үкси уйлансын бу бәндәм, башкаларга зур фикерләр, гыйбрәтләр өстәп яшәсен дип түгел микән алай-болай?! Бик ерактан түгел, Тукайдан гына башлап санасак та андый ятимнәрне, алар милләтебезнең чын мәгънәсендә акыл чүлмәкләре, зирәклек чыганаклары булып формалашалар, башка иҗатташларыннан югарырак булып танылалар. Әйе, бу фикеремне сабый чакта ук ятим калган Хәмитнең язмышы кабат уятты...

Менә аның чираттагы шигырен дә уйга чумып укыйм:

Язмыш сулар кебек аккан,
Инде картлык ишек каккан...
Җилгә очкан күпме тапкан! –
Хәтер җыеп йөри арттан...

И кызганыч та, көлке дә шул адәм баласының гомере... Бер-беребезне таптый-таптый карьера баскычларына ашкынабыз, кемнәргәдер тиешле мал-мөлкәтне үзебез эләктереп калырга ашыгабыз, үзебезгә юл ачу өчен эштәшләрне, дус-ишләрне сатабыз, әләклибез, ялагайланабыз, очлы терсәкләребез белән чордаш вә кордашларыбызның сынын катырып, гөнаһка батып, картлыгыбызга барып терәләбез... Шуннан соң инде мондый гамәлләребезне хәтеребез белән җыя башлыйбыз... Әйе, шактыебызда кара хәтер генә кала. Әгәр дә иманлы, инсафлы, милләтен хөрмәт итә белүче балалар һәм оныклар да тәрбияли белмәсәң, акчага, байлыкка гына чукына-табына торган токым калдырсаң, үзең турында хәтер яңарту түгел, искә дә төшермәячәкләр.

Хәмит Латыйфның бу шигыре кемнәрнедер шушы чама булса да уйландыра алмый икән, димәк, аларга мәгънәле, фәлсәфәле шигырьләрне укып та торасы юктыр...

Авторның чираттагы шигырен укучының өстәленә саласым һәм елмаеп та, житдилек белән дә фикер алышып үтәсем килә. Анысы да бик кыска, әлбәттә... Исеме үк серле тоела – «Төнге әйдәү» дип атала...

Күңелнең пәрдәсен нурладың –
Әллә син Ходаем кошымы?
Идәнгә очканын югганның
Сизмәдем – җан күккә кушылды.

Моны укып чыккач, кемдә нинди хис уянадыр һәм ул иң тәүге чиратта нинди сүзгә игътибар итәдер – белмим, әмма минем күзгә «юрган» сүзе килеп керде. Хәтта телемә урысча сүз дә килеп кушылды. Ягъни, «причум» монда юрган?! Нинди гамәл, нинди хәрәкәт аркасында идәнгә очкан ул? Аның очканын да сиздермәслек нинди хәл-әхвәл булган анда? Җанының күк белән тоташуына шул юрган комачаулаган булганмы? Ә теге күңел пәрдәсен нурлаган зат кем яки нәрсә булган? Табышмак сыман тоела шигырьчек. Әмма серенә төшә белгән кеше өчен беренче мәхәббәт тә, «роман» да, ике җан иясенең Ходай фәрманы белән кавышуы да аңлашыла түгелме?!

Латыйфның шактый шигырьләре йөрәгенең һәрдаим табигать һәм галәм белән тоташ икәнен сиздереп тора. Хәтта күпчелек адәм балаларын көн саен, сәгать саен ялыктырып, рухын алып торучы төтенле-газлы заводларда, гөжләп-шаулап, рухыңны игәүләп яшәүче шәһәрләрдә йомышы да юк сыман. Ул сине һәр шигырендә диярлек тып-тын хәяттәге кара урманнарга алып керер, шундагы чишмәләр, кырмыска оялары янына туктатыр, агачлар, чәчәкләр белән сөйләштерер, пәри кызлары белән таныштырыр, сине һәр күренеш һәм мохит кочагында туктаткалап, күңелеңә яшәү мәгънәсен, гомер фәлсәфәсен салыр. Юк-юк, һич тә озаклап, сүз куертып аңлатмас – үзең белә башларсың, үз акылың белән барып җитү сәләтеңне тоярсың. Шагыйрьнең үз сүзләрен кушкалап та әйтсәм, «караңгылык баскан, өметсезлек талаган, нәфесләрен тыя алмаган, синең хисапка баеп, ыржаешып яшәүче көр адәмнәр мыскылыннан, тирә-ягың тулы юньсезлекләрдән, тыелгысыз нәфесләләр дөньясыннан алып китәр дә ул сине, салкын кереп тулган җаныңны җылытыр...» Шул ук күңелеңне, җәфалардан җәзаланган җаныңны галәм белән тоташтырып куйса да ни гаҗәп – анысын да булдыра Хәмит Латыйф дигән абзагызның тылсымы.

Ләкин... бераз сулыш алып әйтим... ул мине бик еш кына аптырашта да калдыра... Кайчак атналар, айлар буе гел бергә булабыз Хәмит белән, киңәшә-киңәшә яңа китапларыбызны матбугатка әзерлибез. Әлбәттә инде, әсәрләребезгә бәяләр дә бирешәбез. Күңелгә аеруча хуш килгән шигырьләрен укыганда:

– Шәп шагыйрь син, Хәмит! – диюемне дә сизми калам. Ә ул... нәрсә ди?

– Юк, мин шагыйрь түгел. Мин рәссам гына, – дип, көр тавышы белән «мөгрәп» куя да болайрак дәвам итә. – Бу шигырьләр рәсемнәремнән саркып тамган фикерләр, сагышлар һәм бизәкләр генә...

Шаярып әйтүедер, дип, йөзенә текәләм һәм... бары тик җитдилек күрәм. Бу сүзләрен инанып әйтүе кайбер шигырьләреннән дә сизелә. Әйтик, «Бербөтенлек» дигән шигырендә болай ди:

Сукмакларга сары яфрак сибеп,
Көз урманны моңга күмдергән.
Рәссам бага урман күзләренә...
Урман күзе, димәк, тиздән үзе
Кешеләргә багар киндердән.

Билгеле инде, «киндер» дигәнен ясалачак рәсемнең җирлеге – полотносы дип аңлау тиеш. Ни хәл итмәк кирәк, гомерендә меңнәрчә рәсемнәр иҗат иткән, шуларның шактыен – һәр йортның, һәр бүлмәнең түрендә затлы да, нәфис тә бизәк булып торырдайларын – агачка кисеп эшли. Аларны чәч бөртегедәй нечкәлекләр белән кисү өчен нинди генә кораллар кирәктер дә нинди кул чыдарга тиештер, ни дәрәҗәдә түземлек, сабырлык сораладыр! Мөгаен, ул авырлыкларны җиңсә дә, бары тик адәм баласының үз һөнәренә йөрәге белән генә түгел, баш-аягы белән дә гашыйклыгы, үзе сайлаган сәнгатькә бөтен барлыгы белән чумуы җиңәдер. Ул керамиканы да сәнгатькә җигүен әйт тагын!..

Шушы урында, укучымнан гафу үтенеп, әйтергә мәҗбүрмен: миңа, бик күп каләмдәшләремнең иҗатларына бәя биреп тә үзләреннән яки укучыларымнан канәгатьсезлек ишетмәгән, сүз өчен кесәгә кермәгән каләм иясенә бу очракта махсус белгечләрнең ярдәме кирәк икән... Шу-

ларның берсе – яшәлгән гомерен сәнгать дөньясын зәвык белән төпченеп өйрәнүгә багышлаган Розалина ханым Шаһиева болай бәяли Хәмит Латыйфның рәссамлык талантын:

– «Шүрәле», «Изге елан Шахмара» кебек самими образлар – барысы да татарның мәңгелек күңел бизәкләре, аның яшәү ысулын, өметләрен, мәдәни этапларын гәүдәләндергән рухи пантеон... Коры академизм, канатсыз реализм алымнарыннан азат булган бу иҗатның гамәли асылы рәссамның үзенә генә мәгълүм булган серле юллар, алымнар аша алып барылган өч төрле сәнгать алымына нигезләнә. Болар – керамика, агач сырлау, кәгазь яки җитен тукымага майлы буяу белән рәсем төшерү осталыгын сеңдергән гаҗәеп импровизация... Әлбәттә, монда тагын бер компонент – иҗаткәргә ярдәм итү өчен «күктән төшерелгән» магия-тылсым ярылып ята...

Хәзер инде, мондый ук осталык, һөнәри төгәллек белән аңлата алмасам да, күкрәкне киерә төшеп, мин дә куәтле алам галимәнең фикерен: әйе, Хәмит дустымның рәсемнәрен караганда, мин дә сизә идем бит аның тылсымлы зат икәнен! Кайбер рәсемнәргә караш ташлап кына үтә торган кеше булсам да, аның рәсемнәре үзләренә озаклап һәм уйлана-уйлана карарга мәҗбүр итә. Караган саен яңадан-яңа фикерләр өстәлә зиһенеңә, күңелгә сагышлар, өметләр, моңнар иңгәндәй була. Ни өчен? Моңа төгәл җавап бирү ансат түгел. Аларны һәркем үзе карарга, үзе уйланырга тиеш була...

Нишләптер, аның:

– Бу шигырьләр рәсемнәремнән саркып тамган сагышлар, фикерләр һәм бизәкләр генә, – дип кабатлавы да хактыр кебек тоела кайчак. Мәсәлән, менә бу шигыре дә үз рәсемнәрен карап-кайгыртып торган мәлдә күңеленә иңгәндер кебек:

Миһербансыз кара көннәрдә дә
Иманыңны саклап каласы.
Җан туңса да, чәчләр агарса да,
Хак эш өчен һаман янасы...

Аның сәнгать, шигърият белән янып үтүче гомерен үлчәп-барлап утырдым да соңы юлымны болай язып куйдым:

– Ян син, дустым! Синдәйләр янганда, милләт җылына!